## ХАЛЫК ҖЫЕНЫ КАРАРЫ

**Татарстан Республикасы Зеленодольск муниципаль районы Күгәй авыл җирлегенең Тауиле авылында халык җыены нәтиҗәләре турында**

2021 елның 27 ноябре №2

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» Федераль законның 25.1, 56 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы нигезендә граждannар җыены беркетмәсе төзелде, ул 2021 елның 27 ноябрендә 13 сәгать 00 минутта, түбәндәге мәсьәләләр буенча: "2022 елда Зеленодольск муниципаль районы Күгәй авыл җирлегенең Тауиле авылы территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган, I, II төркем инвалидларыннан (ялгыз яшәүче), көндезге бүлектә белем алучы студентлардан, җирлек территориясендә 3 елдан артык яшәмәүче затлардан тыш, түбәндәге эшләрне башкару буенча җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итү өчен 500 сум күләмендә үзара салым кертү белән килешәсезме?:

1. су башнясы территориясен киртәләү

" РИЗА" "КАРШЫ"

Халык җыены нәтиҗәләре турында беркетмә нигезендә:
Сайлау хокукына ия булган халык җыенында катнашучылар исемлегенә 70 кеше кертелгән, тавыш бирүдә 55 кеше катнашкан, бу 78% тәшкил итә.
Тавыш бирү нәтиҗәләре буенча гражданнар җыенында катнашучыларның тавышлары түбәндәгечә бүленде:
җыенда катнашкан 55 кеше «РИЗА» позициясе өчен тавыш бирде; «КАРШЫ» позициясе өчен җыенда катнашкан 0 кеше тавыш бирде.
Бәян ителгәннәр нигезендә, халык җыены карар итте:

1. Татарстан Республикасы Зеленодольск муниципаль районы Күгәй авыл җирлегенең Тауиле авылында халык җыены булып узды, халык җыены нәтиҗәләре – гамәлдә дип танырга.
2. 2022 елда Татарстан Республикасы Зеленодольск муниципаль районы Күгәй авыл җирлеге территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәм даими яшәүче балигъ булган һәр кешедән 500 сум күләмендә үзара салым акчасын кертергә.
3. Алынган акчаларны җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә түбәндәге эшләрне башкару өчен җибәрергә:
   1. су башнясы территориясен киртәләү

4. Әлеге карарны Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында бастырып чыгарырга ( http://pravo.tatarstan.ru ) Татарстан Республикасы Муниципаль берәмлекләре порталы составындагы Зеленодольск муниципаль районының рәсми сайтында ( http://zelenodolsk.tatarstan.ru ) шулай ук Күгәй авыл җирлегенең мәгълүмат стендларында: Күгәй авылы, Үзәк урамы, 29 йорт (администрация бинасы), Күгәй авылы, Тынычлык урамы, 20 йорт (мәдәният йорты бинасы).
5. Әлеге карарны Татарстан Республикасы муниципаль норматив хокукый актлары Регистрына кертү өчен җибәрергә.

Халык җыенында рәислек итүче Ф. Х. Хисаметдинова